**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсын оештыру һәм уздыру тәртибен камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсы турында» 2014 елның 16 маендагы ПУ-479 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 27 июнендәге ПУ-604 номерлы һәм 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсы турында нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә):

5 пунктка түбәндәге эчтәлекле «ж» пунктчасы өстәргә:

«ж) дәүләт граждан хезмәтендә Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак рус һәм татар телләрен нәтиҗәле файдалану.»;

15 пунктның өченче һәм бишенче абзацларын төшереп калдырырга;

19 пунктта «тапшырылган документлар» сүзләреннән соң «, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында тиешле дәүләт хезмәткәре турында булган белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

Нигезләмәнең 2 нче кушымтасын үз көчен югалткан дип танырга;

б) «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсын оештыру һәм үткәрү буенча конкурс комиссиясе турында нигезләмәнең 4 пунктында «һәм мәгариф оешмалары» сүзләрен «мәгариф һәм иҗтимагый оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

в) «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсын оештыру һәм үткәрү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – Конкурс комиссиясе) составында:

Конкурс комиссиясе составыннан Т.В. Забегинаны, А.Р. Зариповны, Б.Ф. Захаровны, А.А. Здуновны чыгарырга;

Конкурс комиссиясе составына кертергә:

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Җамалетдинов Рәдиф Рифкать улын – Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директорын (килешү буенча);

Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен;

Хәйруллин Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын;

Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улын – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министрын;

Шакиров Данис Фәнис улын – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 27 февраль
№ ПУ-188